СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

31 октябрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 123 (8135) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ЯЛ БЕЛӘН ХЕЗМӘТНЕ БӘЙЛӘП, ЯШИЛӘР НОРЛАТЛЫЛАР

## УЙЛАНЫП ТОРЫРГА ВАКЫТ ЮК

***Район хакимиятендә киңәшмә***

**Соңгы кыр эшләренең кайсылары чыннан да соңга кала төсле. Шикәр чөгендерен казып бетергән хуҗалыклар саны артса да, әле шактый ук мәйданнарда эшләре булганнары да бар. Анысын чөгендер казу тәмамланган хуҗалыклардагы техниканы ярдәмгә китереп хәл кылырга булыр үзе. Ә менә казылган чөгендерне чистартып бетереп аны тизрәк заводка озатуда авыл быел да шәһәр халкының ярдәменә мохтаҗ. Шуңа күрә дә район хакимияте <u>пәнҗешәмбе, җомга һәм шимбә көннәрендә чөгендергә массовый чыгуны оештырырга</u> карар кылды. Барлык предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрдән дә хуҗалыкларга эшче куллар белән беррәттән техника белән дә зур булышу сорала. Шулкадәр халыкны кузгатабыз икән, урыннарда да аларның хезмәтен нәтиҗәле оештыру, көннәрнең салкын торуын исәпкә алып, эшләүчеләрне хәлдән килгәнчә кайнар аш - чәй белән тәэмин итү турында да уйларга тиешләр. Элегрәк, мондый кискен хәлләрдә шәһәр халкы авыл кешесенең хәленә керә торган иде һәм бу юлы да авылның кичектергесез бу проблемасын хәл кылудан читтә калмаслар дип ышанасы килә.**

**29 октябрьдә район хакимиятендә хуҗалык җитәкчеләре, агропромышленность комплексының хезмәт күрсәтү һәм эшкәртү предприятиеләре, авылга шефлык итүче башка оешмалар башлыклары катнашында узган киңәшмәдә бу мәсьәлә бар җитдилегендә куелды. Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Ф.М.Дәүләтшин чөгендер уңышын җыю белән беррәттән бөртек өчен кукурузны тиз арада җыеп алу кирәклегенә дә басым ясады, ул уңайдан «Кейс»ларның җитештерүчән эшләве аларга беркетелгән автотранспортның җитәрлек булмавыннан икәнлеген билгеләп үтте. Киңәшмәдә туңга сөрү мәсьәләсе дә бар кискенлегендә куелды, эшкәртелмәгән мәйданнар ишле булган хуҗалыклар һәм аларга шефлык итүче оешмалар җитәкчеләренең аңлатмалары тыңланды. Идарә башлыгы сөт җитештерү һәм хәзерләүнең кимүгә баруын борчылып билгеләп үтте, киләсе ел турында да уйлап, чәчүлек орлыкның сыйфаты турында кайгырту, шикәр чөгендере чәчеләчәк кырларның өслеген тигезләп калдыру турында да кайгыртырга кирәклегенә басым ясады.**

**Киңәшмәдә хакимият аппараты җитәкчесе Ф.М.Галимов авылда реформалаштыру буенча башланган эшне ахырына җиткерү җәһәтеннән башкарасы эшләргә тукталды. Ул хакта газетабызда аерым сүз булачак әле.**

**Халык депутатлары район Советы рәисе урынбасары А.Н.Ельченков якынлашып килүче олы бәйрәм - Татарстан Республикасы Конституциясе кабул ителүнең бишьеллыгын зурлап билгеләп үтүгә бәйле мәсьәләләр турында сүз алды. Ул шулай ук шәхси сектордан сөт җыюны киметмәү, уҗым чәчүлекләрен терлекләрдән таптатуларга каршы кискен көрәшү кирәклеген дә ассызыклап үтте.**

**Киңәшмәдә хуҗалыкларда электр энергиясен тотуга ныклы учет алып баруның мөһимлегенә зур басым ясап үтелде. Бу уңайдан Энергонадзорның Чистай бүлеге вәкиле Җ.Д.Динеев белдерүе тыңланды.**

**Киңәшмә эшенә хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев йомгак ясады.**



*Сүзгә кыска, эшкә оста, дип нәкъ менә Анатолий Ефимов кебекләр турында әйтәләр. Мичурин исемендәге кооперативлар хуҗалыгында эшләвенә күптән түгел генә булса да, егет җитәкчеләр, хезмәттәшләренең тирән ихтирамын казанырга өлгерде. Әлеге дә баягы, эшкә осталыгы, сүзгә кыскалыгы белән. Әйттеме - эшли, сүз куертмый ул. Хезмәт осталыгы да сокланырлык: техниканы әйбәт белә, аны ярата. Чистай совхоз - техникумында алган белемнәре дә техника буенча механик өчен зур ярдәм. Шуңа да Анатолий эшли торган «Авангард» дип аталган 3 нче кооперативта техника һәрчак тулы тәртиптә.*

**Рәсемдә: А.Ефимов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

*«Промстройбанк»ка 75 яшь*

## ЯХШЫГА ӨМЕТЛӘНӘБЕЗ

*Юбилейлар*

Промышленность - төзелеш региональ акционерлык банкы - кыскача «Татпромстройбанк» - Татарстанда иң зур универсаль коммерция банкларының берсе. Бүгенге банк 1992 нче елда СССР дәүләт Промстройбанкы базасында барлыкка килде, ә шул банк системасы үзе 1922 елның 22 октябрендә үк оеша. Күргәнегезчә, аның тамырлары бик тирәндә. Банкның Норлат - Октябрь филиалы республика күләмендәге 13 филиалның берсе һәм аның 1981 елда ачылуы яңа нефть ятмаларын эшкәртү, төзелеш, сәүдә мәйданы артуы белән бәйле.

1994 елда Школьная урамында урнашкан яңа бинага күчкәч филиалда барлык төрдәге банк операцияләре дә башкарыла. Филиал клиентлары үтенече буенча, ә алар бездә 63кә җитте, без РФ, БДБ илләренә акча күчерәбез, тере акчалар белән эш итәбез, халыктан вкладлар алабыз һәм беренче сорауга ук кире кайтарабыз, ссуда бирәбез, коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр кабул итәбез һәм башка операцияләрне гамәлгә ашырабыз. Бүгенге көндә 60-тан артык кеше безгә үз акчаларын тапшырды.

Базар мөнәсәбәтләре чорында, һәркайда җитмәүчәнлектә без һәрдаим эзләнүдә, предприятиеләр белән үзара коммерция мәнфәгатьләрен күздә тотып эшләргә тырышабыз.

Әлбәттә, заманның үзенчәлекле кыенлыклары, үзара түләмәүчелек безнең банк эшчәнлегенә дә шактый гына киртәләр тудыра. Ләкин без, банк хезмәткәрләре барлык проблемалар киләчәктә уңай якка хәл ителер дип өметләнәбез.

**Ф.МӘҖИТОВ,**
**филиал управляющие.**

## ТАГЫН БЕР ТАНТАНА

*Юбилейлар*

Сентябрь аенда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасында санитария - эпидемиология хезмәте оешуга 75 ел тулды. Шул уңайдан Казанда Г.Камал исемендәге татар дәүләт Академия театрында үткән тантанада безнең район вәкилләре дә катнашкан иде.

Инде бүген район дәүләт санэпидкүзәтү үзәгендә әлеге дата уңаеннан зур тантана үткәрелә. Анда әлеге мөһим служба хезмәткәрләре бергә җыелып, бүген бу хезмәт кешеләренә йөкләнгән бурычлар турында сөйләшү үткәрәчәкләр, бәйрәм итәчәкләр.

Санэпидкүзәтү хезмәткәрләре алдында торган бурычлар зурдан. Үзәк хезмәткәрләре халыкның сәламәтлеген саклау һәм профилактикалау, тирә - юнь мохитне сафландыру буенча күпкырлы һәм катлаулы бурычлар хәл итәләр.

Районда исә санитария хезмәте 1950 нче елда оеша. Беренче баш табибы Г.К.Сачкова булган бу учреждение башта райбашкарма комитетының элеккеге бинасында урнашкан була. Шушы еллар эчендә служба зур үзгәрешләр кичерә. Хәзер типовой бинага урнашкан үзәк заманча аппаратура белән җиһазландырылган. Санитария, эпидемиология, профилактик һәм чыганаклы дезинфекция бүлекләре, бактериологик һәм санитар - химик лаборатория - барысы да дәүләт стандартына җавап бирә. Үзәк белемле кадрлар белән дә җитәрлек дәрәҗәдә комплектланган.

... Бүген санэпидкүзәтү үзәгендә тантана. Бәйрәмегез белән, хөрмәтле санитария сагында торучылар.

## ГАКЫЛ, БЕЛЕМ, ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ

*Юбилейлар*

***Үткән атнада шәһәрнең 2 нче рус - татар мәктәп - гимназиясе 60 еллык юбилеен үткәрде. Ул көнне район мәдәният йорты күңелләрендә балачак хатирәләреннән дулкынланган төрле яшьтәге һәм төрле һөнәр кешеләре белән тулы иде.***

Сәхнәдә 60 ел эченнән яңгырагандай мәктәпнең бүгенге пионер яшендәге укучылары башкаруында «Яшь барабанчы чакыруы» яңгырый. Юбилей шулай ачыла. Бәйрәмнең хуҗабикәсе - мәктәпнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Т.С.Макеева артистларча горур тавыш белән кунакларны, лаеклы хуҗаларны президиумга чакыра. Мәктәп директоры А.А.Евлентьев аның ачылу тарихы, үткән юлы, беренче көннән алып бүгенгә кадәрге мәктәпне туган өе иткән укытучылары турында сөйли. Район мәгариф бүлеге мөдире урынбасары В.М.Камалова зур дулкынлану белән күңел түрендә мәңгегә утырып калган укытучылары А.А.Грачева, Л.А.Кирюшкина, Н.Л.Мокеевны атый һәм вәкаләтле кеше буларак районда 2 нче рус -татар мәктәп - гимназиясенең рейтингы зур булуын әйтә, киләчәктә дә аңа лаеклы укучылар чыгаруда ярдәм йөзеннән компьютер классы һәм 20 млн. сум акча бүләк ителүе турында белдерә .Район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова, мәктәпнең шефы райпо идарәсе рәисе М.С.Моратов, 1950 нче елгы чыгарылыш класс укучысы, шуннан олы тормышка юллама алып 40 еллык педагогик стажлы, Ульяновск шәһәреннән кайткан Н.В.Лобашова мәктәпне олы бәйрәме белән тәбрик итәләр. Аннары А.А.Евлентьев юбилейны котлап бүләкләрен китергән предприятиеләр, оешмаларны санап китә: райпо, машина төзү заводы, «Норлатнефть» НГДУсы, «Норлатнефтегазразведка», 53 нче СМУ, 7 нче мәктәп («Камыр батыр»), 127 нче ПМК, азык - төлек комбинаты, икмәк, сөт - май заводларына һәм башкаларга шунда ук олы рәхмәтен белдерә. Алар аркасында мәктәп (авыр заманда монысы да мөһим) йомшак җиһаз, берничә телевизор һәм магнитофон, видеокамера, кухня комбайны һәм башка кирәк - яраклы әйберләргә ия була.

( Ахыры 2 нче биттә).

# ГАКЫЛ, БЕЛЕМ, ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ

**( Ахыры. Башы 1 нче биттә).**

Котлаулардан соң 6 дистә еллык тарихлы мәктәп укытучылары, укучылары хронологик тәртиптә 1937 нчедән алып бүгенгәчә көннәрен композицияләр, җырлар, биюләр, шигырьләр, сәхнә күренешләре ярдәмендә тере итеп күрсәтәләр. Сәхнәгә иң авыр еллар-ачлык - ялангачлыкны, фәкыйрьлек җәфаларын җиңеп белемгә омтылган 40нчы, 50нче, 60 нчы елларда мәктәпне тәмамлаган иң өлкән укучыларын чакырып үз бүләкләрен тапшыралар, аларга җырларын багышлыйлар.



Мәктәп авыр еллар кичерә. Бу хакта хәрби хатирәләр сөйли: эвакогоспиталь буларак сугыш белән күзгә - күз очраша. Укучылары парта артыннан сугышка китәләр - Р.Н.Хөснетдинов 9 класстан фронтка юнәлә, аннан кайтып мәктәпне тәмамлый һәм гомере буе шунда укытучы булып эшли. Мәктәпнең тере тарихының бүген урыны түрдә.

Вакыт күпме генә читен булмасын, мәктәп төп вазифасын башкару өчен бар көчен куя. 1945 елда чыгарылыш класста 10 кеше исәпләнә. Алдагы елларда мәктәпне тәмамлаучылар елдан - ел күбәя - 50 нче елда 20 укучы. Нәкъ шул елларда укучылар чирәм җирләр эшкәртергә ашкынып китәләр. Шул елларда тормышта уңышка ирешкән илнең төрле почмакларындагы укучылар исемнәре атала. Алар хәрбиләр, галимнәр, зур предприятие җитәкчеләре...

Сәхнәгә чал чәчле ветеран укытучылар күтәрелә: мәктәп юбилее - аларның һәркайсының юбилее ул. Меңләгән укучыларны аң - белем сукмагына алып кергән, олы тормышка аяк бастырган ветераннар өчен «Мәктәп йортыннан киткәч» җыры яңгырый.

Алга таба мәктәпнең ялкынлы комсомол еллары, энтузиастлар - агитбригадалар, җырлый да, бии дә, укырга да сәләтле яшьләре хакында сүз бара. «80 нче елларга алтын һәм көмеш медальләр яңгыры ява» дип атый алып баручы ул чорны кыска һәм мәгънәле итеп. Алар арасында кемнәр генә юк бүген: укытучылар, нефтьчеләр, төзүчеләр, врачлар - болары Нурлаттагылар гына әле.





Соңыннан сәхнәдә мәктәпнең бүгенге укытучылары, укучылары «Бу беркайчан да кабатланмый» җыры белән юбилейны ябалар. Хәер, чакырылган кунаклар өчен ул мул табында дәвам итә әле.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА**

**Рәсемнәрдә: бәйрәмнән күренешләр.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

***Районда газлаштыру программасын үтәүнең барышы, аның аерым нәтиҗәләре турында хәбәр иткәли торабыз. Әмма бу мөһим эшнең нәтиҗәсе турында халык иң элек теге яки бу торак пунктның йорт - фатирларында челтәр газы ягыла башлауга карап кына фикер йөртә бит. Ә зәңгәр ягулыкның теге яки бу авылга килеп җиткәнче дә никадәр катлаулы һәм зур юл үтүе турында да белеп тору мәслихәт. Район хакимияте авылларны газлаштыруны якындагы ике елда нигездә төгәлләү бурычын алга куйган һәм шул юнәлештә җитди эш алып барылган шартларда бигрәк тә. Район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең капиталь төзелеш бүлеге башлыгы М.Х. Миннебаев белән әңгәмәбез дә шул хакта.***

## *2000 нче елга - газ!*

# *Иң мөһим бурыч*

**- Минтәсим Харисович, иң элек бүгенгә район авылларының газлаштыру дәрәҗәсе турында берничә сүз әйтик әле.**

- Табигый газ 92 торак пунктның 26сына кертелгән бүген, шул исәптән 15 авыл тулысы белән газлаштырылган. Авыл җирендә барлыгы 3381, ягъни һәр өченче йорт һәм фатирда челтәр газы яна. Барлык авыллары да тулысы белән газлаштырылган хуҗалыклар дүрт - «Дуслык» Синдряков исемендәге, «Родина», Хафизов исемендәге ассоциацияләр. (Дөрес, аларның торак пунктлар саны иң күп булган соңгысында 17 йортлы Тарн - Варн поселогы киләсе елга газлаштырылып бетерелячәк). Зур авыллардан Кизләү, Егоркино, Яңа Иглай тулысынча газлаштырылган, Югары Норлатта да берничә генә йорт калып бара һәм ел ахырына кадәр алары да челтәр газына тоташтырылачак. Урта Камышлы, Абляскино авылы 80, Вишневая Поляна, Түбән Чаллы, Киекле авыллары 60 процентка, Зирекле, Фоманың биштән икесе, Каравыл Тавының өчтән бере газлаштырылган.

**- Ә икееллык киеренке программаны гамәлгә ашыру барышында башкарылган эшләрдән кайсылары игътибарга лаек?**

- Узган ел ахырында Фомада газ кертү җанланып, авылның яртысыннан артыгына челтәр ягулыгы бирелүе турында беләсез инде. Ә 1997 елгы программада барлыгы 122 километр чамасы, шул исәптән торак пунктлар арасында 55 километр тирәсе газүткәргеч сузу, барлыгы 1900, шул исәптән авыл җирендә 1300 фатирга газ бирү каралган. Тугыз айда барлыгы 36 километрдан артыграк, шул исәптән авыллар арасында 13 километр чамасы газүткәргеч файдалануга бирелде. Бүгенге көндә тагын 68 километрлап газүткәргеч әзерлек стадиясендә һәм шул исәптән торак пунктлар арасында газүткәргечләр быелга планлаштырылганнан да күбрәк булачак. Аерым алганда, Төрнәскә 12 чакрымнан күбрәк, Сәләнгешкә 9,6, Мамыкка 8,2, Әлмәт һәм Якты Күлгә 6шар чакрымнан артыграк, Кычытканлыга 4 км. газүткәргеч сузылды. Ел ахырына кадәр барлыгы 18 торак пунктка газ бирү күздә тотыла. Газлаштырылган фатирлар саны шәһәрдә инде бүген үк планлаштырылган күрсәткечкә якын (550), ә авыл җирендә әлегә 273 фатир газлаштырылды. Алар арасында Кызыл Октябрь поселогы, Зирекле, Биккол, Якушкино, Андреевка авыллары бар.

**- Ә менә быел газ кертү күздә тотылган 18 авылның кайсыларында эш тәмамлану алдында соң, ягъни мәсәлән, кайсы авылларда газ берничә йортта булса да быел ук кабыначак дип ышандырырга мөмкин.**

- Ел ахырына кадәр Колбай Мораса, Сәләнгеш, Кычытканлы, Төрнәс һәм Түбән Норлат авылларында яшәүчеләр табигый газның уңайлыгын тояр дип ышанырга була. Моннан тыш Киекледә, Зирекледә, Фомада, Бикколда газ кертелгән йортлар саны шактый ишәячәк, Урта Камышлының да калган йортларына быел газ бирелер дип өметләнәбез. Әле тагын берничә торак пунктта челтәр газы булыр дип ышанабыз. Гомумән алганда быел авыл җирендә былтыргыдан күпкә артыграк гаилә газлы булачак һәм авылларны газлаштыру дәрәҗәсе быел 40 процент чигенә җитәчәк.

**- Ә бу эштә нинди тоткарлыклар бар, финанс мәсьәләсеседер инде...**

- Мәгълүм булганча, районда газ кертү буенча подряд эшләре белән 6 оешма шөгыльләнә. Шуларның бишесе - читтән чакыртылган подрядчылар. Дөрес, Димитровградның 14 нче махсус участогы, «Газпромстрой» участоклары - безнең күптәнге партнерларыбыз. Аларның икенчесе быел Әмзәдә, шулай ук шәһәрдә йортларга газ торбалары сузу белән интенсив шөгыльләнде. «Востокмонтажгаз» АООТынннан ген. директоры (В.В.Бартенеев) безнең районда берьюлы өч оешма эшли. Алар Богдашкино, Мамык, Сәләнгештә зур эш башкардылар, шикәрчеләр поселогының өч урамындагы иң «кайнар» ноктада да алар эшли. «Татгазстрой» башкара торган эш күләме дә зур. Эш күләме зур булгач, аның өчен түлисе дә күп икәнлеге аңлашыла торгандыр. Дөрес, район җитәкчелеге подрядчылар белән исәп - хисап ясау өчен төрле мөмкинлекләрне таба тора. Әмма хәзер иң катлаулысы йорт хуҗаларыннан акча җыю.Шуңа күрә потенциаль кулланучыларның бу мәсьәләгә җитди карап активрак булулары сорала.

Икенче бер төп тоткарлык - кайбер хуҗалык җитәкчеләренең бу эшкә мөнәсәбәте бик җитди булмаудан. Бу җәһәттән элегрәк тиешле проект - смета документлары әзерләүне суза килүчеләр турында әйтә торган идек. Хәзер исә газ керттерү һәм газүткәргеч системасын файдалануга бирү чорында гаять мөһим булган мәсьәлә - техник күзәтү буенча һәм газ хуҗалыгы өчен җаваплы кешеләр әзерләү. «Әлмәт», «Татарстан», «Заветы Ильича», «Үрнәк», «Комбайн»да, сөт - май комбинаты, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында йортларга газ бирү нәкъ менә шул сәбәптән тоткарланырга да мөмкин әле. Тагын бер нәрсә. Хәзер урыннардагы газ хуҗалыгын «Норлатгаз» балансына тапшыруга әзерлек эше бара. Мичурин исемендәге, «Родина» хуҗалыкларында бу мәсьәләгә җитди карыйлар. Тик күпчелек хуҗалыкларда газүткәргечләрне тиешле тәртипкә китерү эше белән чынлап торып шөгыльләнмиләр әле.

**- Ике еллык газлаштыру программасына райондагы 82 торак пункт кертелгән. Азмы бу, күпме?**

- Киләсе ел ахырына кадәр авылларның биштән дүрттән күбрәген газлаштырып бетерү күздә тотыла. Әмма газлаштыру эшенең гомуми масштаблары тагын да колачлырак булачак - киләсе елда районның барлык почмакларында да газлаштыру эше алып барылачак. Иң ерак Елаур төбәгенә дә газ торбалары ташыла инде, урман хуҗалыгы карамагындагы авылларда да эш бара. Кыскасы, якын арада бөтен районны газлаштырып чыгу - реаль. Район җитәкчелеге бу мәсьәләне даими игътибар үзәгендә тота, урыннардагы җитәкчеләр дә ул эшкә бар җитдилегендә карасалар, гаять мөһим бу программаны башкарып чыгу һич тә кулдан килмәслек нәрсә түгел.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ сөйләште.**




## Исәнмесез, нәни дуслар!

***Менә тагы без сезгә күчтәнәч китердек. Авыз итеп карагыз әле, тәмле микән ул? Инде «күчтәнәч»не тагы да баерак итәргә теләсәгез, үз язмаларыгызны безгә юллый аласыз, ә әлегә «Нәниләргә күчтәнәч» сезнең игътибарга!***

### Бездә кунакта - Гакыйль СӘГЫЙРОВ

## «Тартык» авазлар

Икенче класста укучы Раил мич арасына чаршау артына - тынычка кереп баскан да «Татар теле»ннән өйгә бирелгән дәресен өйрәнә. Китабыннан берничә сүз укый да, чаршау читен ачып, апасы уйнап утырган телевизор экранына күз сала:

- Алгарак ат, алгарак...

Һәм тагын укыганы ишетелә:

- Тартык авазлар: б - п, г - к, ж...

Чаршау чите ачылып, Раилнең борыны күренә:

- Өскә мен! Өскә! Хәзер - аска! Эх, үзем булсам!..

- Үзем дә беләм... Син китабыңа кара...

Мич арасыннан тагын:

- Тартык авазлар... тартык авазлар дигәне ишетелә һәм күп тә түгел аралыктан:

- Ат инде, апа, танкыдан ат! Эх, мазила! - дип кычкырып, өй эчен яңгыратып җибәрә малай.

- Өйрәтмә - беләм, өлгерми генә калдым...

- Тартык авазлар: ж - с, д - т,...

Мич башында - җылыда каткан буыннары йомшап, сызлаулары бераз китеп, йокымсырап киткән карт әбисе Раил тавышына уянып китте һәм онытыгының, һаман әле «Тартык авазлар» дип кабатлавын ишетеп, эче пошты:

- Яп - яңдый укып барган балаларга нәрсә алып бирделәр бит, ходаем. Сабакларыннан күңелләре сүрелде, кулларына китап тотып караганнары юк, күзләренә һич ни күренми: өннәре - төшләре шул «деңделдек». Шул ике сүзне сәгать буе өйрәнә ләбаса, алай да башына керми - әнә кая ич бала күңеле. Белгәннәрен дә онытып бетерәчәкләр болай булса. «Тартык авазлар» гына булып калмасалар ярар иде, раббем,- дип сукранды.

Шулай да Раил бер дә «тартык аваз» булып алырга теләмәгән - өйрәнгән. Һәм икенче көнне «тартык авазлар»ны сөйләп дәү генә «бишле» алып кайткан иде.

## Бозлы яңгыр

Бу болытка
Ни булгандыр -
Коя гына
Бозлы яңгыр.
Бозлар җиргә
Күп төшәләр,
Тып - тып
Тып - тып
Сикерешәләр.
Бер чебеш
Шатланып чаба:
- Карагыз, ди,
Борчак ява!..
Борчак ява!..



# Бәрәңге буреләр, кабак өйләр...

Без, Фома урта мәктәбе укучылары мәктәбебездә традицион рәвештә үткәрелә торган «Уңыш бәйрәме»н алдан ук әзерләнеп көтеп алдык. Ниһаять, 1 нчедән алып 7 нчегә кадәр һәр класска ике төрле өстәл әзерләргә «боерык бирелде». Берсе камыр ризыкларыннан сый - нигъмәтләр белән тулы булса, икенчесе яшелчә, җиләк - җимешләр ярдәмендә иҗат ителгән сувенирлардан сыгылып торырга тиеш иде.

Класслар залга чыкканда өстәлләр буп - буш иде. Күз ачып - йомганчы алар бәрәңгедән ясалган дию пәриләре, куркыныч бүреләр, кошлар, тәрәзәләреннән шәм яктысы күренгән кабак өйләр, көймәләр, аларда йөзеп ял итүче кешеләр... белән тулды. Нәрсә генә юк иде биредә. Без кайсын карарга белмәдек. Күренеп тора: һәр укучы яшелчәләрне әшкә яраклы итү өчен, бөтен фантазиясен җигү өчен зур көч һәм тир түккән, һәр сувенирга җан бирергә тырышкан, яшелчәләрнең төрлесеннән файдаланган. Икенче өстәлләрдә камыр ризыклары - пар күтәрелеп торган бәлешләр, мул итеп бал ягылгангадыр инде, утта алтын күк ялтырап торган тортлар, дөге, йөзем исләрен аңкытып торган гөбәдияләр, суыткычта җәй хозурлыгын саклаган җир җиләкләре, викторияләр... Өстәлләрне карап туя алмадык, ә менә жюрига тагын да кыенгарак туры килде. Шулай да кат - кат караганнан соң башлангыч класслар арасында беренче урынны 2 нче класска, олыракларда 6 нчы класска бирделәр.

Без беренче урынны эләктергәч, сый - нигъмәтләребезне аеруча куаныч белән ашханәгә ташыдык. Чөнки бәйрәмнең икенче өлеше анда өстәлләр артында дәвам итте. Һәр класска 2 - 3 концерт номеры әзерләргә кушылган иде. Моңсу да, бик күңелле дә көзге җырлар җырланды, сары яфрак күк киенгән кызлар оча - оча биеделәр, Көзбикә турында иксез - чиксез шигырьләр сөйләделәр.

«Уңыш бәйрәме» әле кичә генә булды кебек, тик мин аны сагындым да инде.

**Айгөл МӨХӘММӘТШИНА,**
**6 нчы класс укучысы, «Яшь көч» түгәрәге әгъзасы.**




## КАДЕРЛЕ БАЛАЛАР!

***Сезнең «Салават күпере», «Сабыйга» журналларын бик яратып укуыгызны беләбез. Хәзер нәкъ менә газета - журналларга язылу бара. Сез әти - әниләрегез белән киңәшеп, киләсе елга да аларны алдыру хәстәрен күрергә онытмадыгызмы?***

## Табышмаклар



Тук - тук итә, тукылдата,
Яссыны шакылдата,
Тукылдата пыр туза,
Бөтен тынлыкны боза.

Юан нечкәне тукмый,
Бер тукмый да, бер туктый,
Ут чәчә, кыза нечкә,
Үзе гел уза эчкә.

(Кадак, чүкеч, такта)

Үзе тотмый, үрелми,
Куллары да күренми.
Әллә чеметә, тешли,
Безне бала - чаганы,
Учы белән чагамы?
Кулын чакса да шактый,
Әби аны бик мактый.
Төреп кайта яулыкка:
Файдалы, ди, саулыкка!

(Кычыткан)

Бәйләми дә, текми дә,
Каемый да, чикми дә,
Энәләре үзендә,
Җитә, диләр, йөз меңгә.

(Керпе)



# Артур кайгысы



Өченче көн инде Артурның күзеннән яшь кипми. Нәрсәгәдер үртәлеп түгел, олыларча эчтән әрнеп, хәсрәтенең ачылыгын йөрәге белән тоеп елый ул. Хәсрәте дә зур шул: аларның песи балалары үлде. Сап - сары төстәге, йомры йомгак шикелле бөгәрләнеп йөгереп йөрүче, йомшак тәпие белән әле Артурның, әле апасының куенына сыенырга торучы, аларның аяк тавышларыннан танып, ишек янына каршы алырга йөгерүче Майкл өченче көн инде җир куенында ята.

- Улым, ярар, тукта инде. Яңа песи баласы алырбыз,- дип юатмакчы әнисе улының яшькә чыланган йөзен күкрәгенә кысып.

- Ул барыбер Майкл булмый инде. Мин Майклны гомеремдә дә онытмам,- ди малай үксүеннән туктамыйча. - Әле мин бүген аның каберенә бардым, чәчәкләр куйдым.

- Нинди чәчәкләр куйдың соң?

- Кырдан ромашкалар җыйдым. Майкл аларны яратыр бит.

Артурның күзеннән яңа бөртекләр атылып чыкты. Кечкенә песи баласы үзенең шундый тугъры дусты булганлыгын белсә икән! Юк шул, ромашкалы кабер астында ятучы бу җан иясе аны бәяли алмас. Әмма кешеләр бәяләр. Нәни песи баласына шундый мәхәббәт һәм тугърылылык белән караган малай дуслык, иптәшлек, вәгъдәлелек кебек төшенчәләрнең тирәнлеген аңламас дисезме?

Артур әле бу турыда сөйләсәң дә аңларлык яшьтә түгел. Аннары, кайгысы да зур. Әни кеше генә аның ачы хәсрәтенең никадәр самими, эчкерсез булуын күреп, улының сизгер җаны, нечкә күңеле булуына сөенеп куйды.

**С.НУРУЛЛИНА.**

## Игътибар ит әле

### Бер карасаң - малай,



### икенче карасаң - бабай

# Шырпыны тотса бала кулына...

Балаларның шырпы белән шаяруы янгын чыгуның төп сәбәпләренең берсе булып тора. Быел районда теркәлгән янгын очракларының өчесе, мәсәлән, шул сәбәпле килеп чыкты. Әлеге янгыннар зур матди зыян китерде. Май урталарында, мәсәлән, Тәрнәс авылында яшәүче нәни Олег Денисов өй чардагына менеп, шырпы белән уйнаган. Нәтиҗәдә өйнең түбәсе янып китә. Мондый очраклар тагын да бар. Шулай ук балаларның шырпы белән уйнауларын кисәтүдә ата - аналарның роле зур. Ни өчен дигәндә, баланың психикасы һәм тәртибе өлкәннәр үрнәгендә формалаша. Шуңа да өлкәннәрнең үзләренә янгын куркынычсызлыгының элементар кагыйдәләрен сакларга кирәк. Яшь балаларны ябык өйләрдә күзәтүчесез калдырмау, шырпы, шуның ише тиз кабынучан әйберләрне аяк астында тотмау да хәерлерәк. Балаларга янып торучы мичләр, кабызылган газ плитәләре, электр приборларын карарга кушып калдыруның да ахыргы нәтиҗәләре күңелсез булуы мөмкин.

Гомумән, балаларның шырпы белән шаяруын кисәтүдә өлкәннәрдән күп нәрсә тора. Шуңа да урамда учак ягып уйнаучы балаларга битараф булмагыз. Бүген бу эшне башкалар эшләсә, иртәгә алар урынында сезнең балаларыгыз булырга, яисә сезнең мал - мөлкәтегез куркыныч астында калырга мөмкин. Мәктәпләрдә, балалар бакчаларында балалар арасында аңлату эшләре алып бару, яшь янгын сүндерүчеләр дружиналары булдыру да янгыннарны кисәтүдә зур роль уйнар иде.

**Р.ИЛЬЯЛОВ,**
**дәүләт янгын күзәтү инспекциясе инспекторы.**



Рәсемгә татар милли киеменнән төшкән бу хатын - кызны артист дип уйлыйсыздыр инде сез. Ялгышасыз, тәрбияче ул. 15 нче «Алсу» балалар бакчасында эшли ул. Болай киенеп йөрүе дә бик сирәк. Рәсемгә исә «Елның иң яхшы тәрбиячесе» конкурсында катнашканда төшергәннәр иде үзен. Резидә Хәлимовна бик уңышлы чыгыш ясады анда. Хәер, конкурсларда, бәйгеләрдә генә түгел, тәрбияче балалар белән дә һәрчак актив, иҗади эшли бит. Теләсә нинди киемне кырт иттереп тегә, рәсемдәгедән һич ким түгел иттереп чигә, үз куллары белән уенчык, төрле кораллар ясый белүен, җыр - моңга сәләтле булуын искә алып, конкурска димләделәр бит аны хезмәттәшләре.

Балалар белән эшләү осталыгы турында сөйләп торасы да юк инде. Кечеләр телен аңлаучы, өлкәннәрне олыларча хөрмәтләүче педагог үз группасы - урта яшьләрдәге балаларга ныклы тәрбия бирү өчен эшендә нинди чаралар гына кулланмый. Нәтиҗәсе исә һәрчак көтелгәнчә - яхшы була. Әле менә бу көннәрдә үзе җитәкләгән «Яшь сәнгать осталары» түгәрәге әгъзалары белән быелгы беренче иҗади хезмәт җимешен сәхнәгә куярга җыена.

Боларга тәрбияче Резидә Гомәрованың Яр Чаллы педагогия училищесын тәмамлавын, дистә елга якын педагогик стажга ия булуын өстисе кала. Норлаттагы «Алсу»да хезмәт стажы зур түгел әле аның. Кайбыч районының Чүти авылы кызының тормышка чыгып Норлат якларына килеп урнашуына да күп түгел бит әле. Әмма хикмәт монда түгел, ә аз вакытта да күп эшләр башкаруы хакында.

**Рәсемдә: Р.ГОМӘРОВА.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Мотоцикл ияләре игътибарына!

**Һәр елны Октябрь эчке эшләр бүлегенең ДАИ штраф стоянкасына юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен 70тән артык мототранспорт чаралары куела. Еш кына әлеге транспорт ияләре аларны учетка кую, үз артларына яздыру белән шөгыльләнмиләр. Кайчакта «әсирлектәге» ике тәгәрмәчле атларын алырга теләмәүчеләр дә табыла. Кыш якынлаша, мотоцикллар кар астында калачак, бу исә аларга тагын да зуррак зыян салачак.**

**Гражданлык кодексы нигезендә (226 нчы статья, 1 нче бүлек) 6 айдан артык стоянкада торган транспорт чаралары тиешле карар чыгарылгач сатуга куелалар.**

**Мототранспорт чаралары ияләренә мотоциклга документлары белән ДАИга килүләрен сорыйбыз.**

ДАИ.

**Н.Октябрь ОСТО район Советы «В», «ВС», «ДЕ» категорияләре буенча шоферлар әзерләүгә кабул итә башлады. Укырга теләүчеләрнең Норлат шәһәре 60 лет Октября ур., 16 адресы буенча 4 нче ноябрь көнне 18 сәг.тә безгә килүләрен сорыйбыз. Белешмәләр өчен телефон: 2 - 25 - 80.** Лицензия сериясе А - 96, № 024826, 14.10.97 елда бирелгән.

**«Газпром» РАОсы акцияләре сатып алабыз яки ВАЗ автомашиналарына алыштырабыз.**
Тел.: 5 - 15 - 91.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Бу көннәрдә гаиләбезнең кадерле кешесе Яңа Әмзә авылында яшәүче **Фәнил Фаиз улы Низамовның** туган көне. Олы бәйрәме белән чын күңелдән котлап, без аңа сәламәтлек, гаилә бәхете, җан тынычлыгы, озын гомер телибез.*



*Яшәү маягы син безнең өчен,*
*Кешелегең белән үрнәк син.*
*Мең - мең рәхмәт тәрбияңә, энем,*
*Безнең өчен һәрчак кирәк син.*

***Иң изге теләкләр белән әниең, хатының, балаларың исеменнән апаң Сания.***

## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч рәвештә Советская ур.,104-4 адресы буенча 2 бүлмәле фатир.**

***

**4х6 метрлы цинкланган калай белән тышланган чанадагы гараж.** Адрес:Комсомольская ур.,24.

***

**1985 елгы әйбәт хәлдәге ВАЗ-2105.** Тел.:5-21-65.

***

**1993 елгы ВАЗ-21093 һәм ВАЗ-21011.**
Адрес:Суворов ур.,115,16 сәг.кә кадәр.

***

**Калай белән тышланган яхшы хәлдәге чаналы гараж.** Тел.: 5 - 43 - 44.

***

**Кулланышта булган җиһаз.** Тел.: 2 - 16- 59.

***

**Яхшы хәлдәге агач йорт, 20 сутый участогы бар.** Чулпан авылында Усмановка мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 3 - 82 - 83.

***

**Көнчыгыш микрорайонында төзелеп бетмәгән гаражы белән йорт өчен җир участогы.** Мөрәҗәгать итү өчен адрес: Завод тыкрыгы, 9 - 29, 17 сәг.тән соң.

***

**Әйбәт хәлдәге йорт, 12 сутый җире, йорт яны корылмалары, мунчасы, коесы, базы бар.** Тел.: 2 - 27 - 52, 2 - 21 - 35.

***

**ВАЗ - 21011.** Адрес: Школьная ур., 33 - 33. Тел.: 2 - 17 - 29.

***

**Әйбәт хәлдәге, 1972 елгы «Москвич - 412».**
Адрес: Горький ур., 3.

***

**Ашыгыч рәвештә УАЗ - 469 һәм НИВА, бәясе килешү буенча.** Адрес: Дружба ур., 69 - 58, тел.: 5 - 20 - 71, 17 сәг.тән соң.

***

**3 х 5 метрлы мунча бурасы, бәясе 2 млн. сум.** Адрес: Садовая ур., 2а - 49.

***

**ВАЗ - 2106.** Адрес: Пионерская ур., 2а - 12.

***

**1997 елның маенда чыгарылган ВАЗ - 21083.**
Тел.: 5 - 14 - 44.

***

**1997 елның июлендә чыгарылган НИВА - 21213.**
Тел.: 5 - 19 - 35, 8.00дән 17.00 сәг.кә кадәр.

***

**Тимер юл буенда Линейная урамында 70 нче позицияле гараж.** Адрес: Завод тыкрыгы, 9 - 15, 17.00 сәг.тән соң.

***

**ВАЗ - 2101.** Адрес: Ленин ур., 24 - 12, тел.: 2 - 11 - 50, 18.00 сәг.тән соң.

***

**Ашыгыч рәвештә «Алмалык» бакчачылык ширкәтендә дача. Мунчасы, коесы, үсентеләре бар.** Адрес: Советская ур., 189 - 36.

***

**1995 нче елгы ГАЗ - 53 йөк машинасы, тентланган, дизель ягулыгында эшли.** Тел.: 2 - 19 - 19.

# Ипи-тоз, ачык йөз

Кайчандыр Татарстанның атказанган сәүдә эшлеклесе И.И.Туишев җитәкләгән хәзерләүләр конторасы Татарстан Республикасында гына түгел, Россиядә дә иң алдынгы конторалар хисабында иде. Биредә берничә тапкыр эшлекле семинарлар оештырылды. Республиканың барлык хәзерләүләр конторалары тәҗрибә алу өчен безнең районга җыелалар иде. Үзгәртеп кору җилләре хәлебезне тагын да алга җибәрмәде, киресенчә, бөтен ирешелгәнне дә юкка чыгарды. Ит комбинатын хәтерләткән терлек сую урыннары, аны тиешле сыйфатын югалтмыйча саклый торган суыткычлары - һәммәсе дә эшкә яраксызга әйләнде. Туишевтан соң берничә җитәкче алышынса да контора өчен дә, халык өчен дә алга китеш күренмәде. Биредәге эшчеләр хезмәт хакын ала алмады, ә үзеннән арткан продукцияне тапшырган халык акчасын алу турында өметне өзеп конторага якын килмәскә тырышты. Ә менә соңгы вакытта Җ.З. Әхмәдиев директор итеп билгеләнгәч безнең күңелләрдә контораның терелеп китәсенә өмет туды. Аның халык белән мөгамәләсе, эшләү ысулы, халыкны эшкә тарту осталыгы контораның элекке данын яңадан кайтарыр дигән ышаныч барлыкка килде. Безгә, ветераннарга аның белән өлкәннәр көнендә якыннан танышырга туры килде. Бу көнне безне әлегә кадәр күрелмәгән олылау белән хөрмәтләделәр. Бәйрәм мул табын артында җырлап, биеп барды, аннары мул итеп күчтәнәчләр таратылды. Ипи, тоз, ачык йөз, ди бит халык. Теләгәч акчасы да, ризыгы да - һәммәсе дә табылган, хәтта ресторан ишеге дә безнең өчен ачык иде. Кеше кая гына, кем булып кына эшләсә дә иткән игелеге, югалмас гамәле генә истә кала бит. Җитәкченең халыкка игътибарлы, җылы мөнәсәбәттә булуы да эзсез калмас.

**В.МИНХӘЕРОВ,**
**хезмәт ветераны.**

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**3 бүлмәле фатирны өстәмә түләп 2 бүлмәлегә алыштырам.** Адрес: Советская ур., 195 - 15 (төштән соң).

***

**Спиченков Сергей Александрович исеменә бирелгән АГМ 810624 номерлы машина йөртү таныклыгын һәм 797624 номерлы вакытлыча рөхсәт кәгазен югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**Сергеев Александр Иванович исеменә машина йөртү таныклыгы һәм ике техпаспорт табучыны бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Адрес: Промышленная ур., 18 - 1.

***

**Самара шәһәрендәге өч бүлмәле яхшы планировкалы хосусыйлаштырылган фатирны Норлатта ике бүлмәле фатирга яки килешү буенча газ белән җылытыла торган өйгә алыштырыла.** Адрес: Советская ур., 102 - 9.

**Өч бүлмәле фатир 1 һәм 2 бүлмәлеләргә алыштырыла, вариантлар мөмкин.** Тел.: 5 - 21 - 45, 17.00 сәг.тән соң.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 7, 21ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.